**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 31 май № 324

г. Казань

«Болгар» шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкаласы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә урнашкан дәүләт мөлкәте өчен аренда түләве буенча ташламалар билгеләү турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 ел, 25 июнь, ФЗ-73 нче Федераль законның $5^1$ статьясындагы 1 нче пунктның 3 пунктчасы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү хакында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль законның 18 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 ел, 26 июль, ТРЗ-35 нче Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 9 декабрь, 1018 нче карары белән расланган 2010 – 2018 елларга «Мәдәни мирас – Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар» комплекслы проекты чараларын тормышка ашыру кысаларында «Болгар» шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкаласы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясен үстерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына (алга таба – арендага алучы) «Болгар» шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкаласы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә урнашкан, Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган һәм «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында теркәлгән күчемсез мөлкәт объектлары өчен (җир кишәрлекләреннән тыш) кимендә биш елга төзелгән аренда шартнамәләре буенча аренда түләве буенча түбәндәге ташламаларны билгеләргә:

аренда шартнамәсендә билгеләнгән аренда түләве күләмен аренданың беренче елы өчен 70 процентка киметү;

аренда шартнамәсендә билгеләнгән аренда түләве күләмен аренданың икенче елы өчен 50 процентка киметү.

2. Арендага алучы аренда шартнамәсе буенча йөкләмәләрен үтәмәүгә бәйле әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән объектлар арендасы шартнамәсен вакытыннан алда өзгән очракта, аренданың беренче ике елы өчен аренда түләве бу карарда билгеләнгән аренда түләве буенча ташламаларны кулланмыйча кертелергә тиеш дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\324.docx